ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әтнә муниципаль районы
Олы Әтнә авыл җирлеге
Советы

422750, Әтнә муниципаль районы
Олы Әтнә авылы, Совет урамы, 1
тел. 2-15-68, факс 2-15-68

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Атнинский муниципальный район
Совет Большеатнинского сельского
поселения

422750, Атнинский муниципальный район
с.Большая Атня, ул. Советская, 1
тел. 2-15-68, факс 2-15-68

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» ноябрь 2024 ел. № 10

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Олы Әтнә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 2024 елның 01 декабрендә сәгәт 10.00 га Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Олы Әтнә авылында Б.Зиганшин 1 дән 57 гә кадәр, Гагарин, Газовая, Дуслык, Зилина, Интернациональная, К.Маркс 1 дән 25 гә кадәр йортлар, К.Якуба, Комсомольская № 1 дән 14 гә кадәр йортлар, Кустар, М.Сәлимзянова, № 2 дән 15 гә кадәр йортлар, Мира, Наратлык, Октябрьская № 1 дән № 18 гә кадәр йортлар, Пионерская № 1 дән № 15 гә кадәр йортлар, Пролетарская, Пушкин, Эшчеләр йортлары № 1 дән № 2 гә кадәр, Радио, С.Хаким, Сарман, Совет йортлары № 3 дән № 35 гә кадәр, Тугай, Тургай, Ударников, Ферма, Чулпан, Ш.Мәрҗани, Электро урамнары буенча теркәлгән үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының **беренче этабын билгеләргә**.

2024 елның 01 декабрендә сәгәт 11.00 га Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Олы Әтнә авылында Б.Зиганшин 4а, 6, 59-89нчы йортлар, Дулкын, к. Маркснның 12-104нче йортлар, Казан, Коммунаров, Комсомол 15-48 йортлар, М. Сәлимҗановның 16-51нче йортлар, Нариман, Новая, Октябрь 20-28 йортлар, Пионер 16-44 нче йортлар, Рабочая 5-9нче йортлар 13нче номерлы, 51нче номердан 81нче номерлы Совет йортлары, татарстан, Тукай, яшьлек.урамнары буенча теркәлгән үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының **икенче этабын билгеләргә**.

1.1. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Олы Әтнә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты 1 декабрь 2024 ел 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр **беренче этабы**;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты 1 декабрь 2024 ел 11.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр **икенче этабы**;

- үткәрү урыны — Олы Әтнә авылы, Совет урамы, 1 йорт урыны **беренче этабы**;

- үткәрү урыны — Олы Әтнә авылы, Новая һәм Татарстан урамнары киселеше, Илсоя киоскы янында **икенче этабы;**

1.2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2024 елның 25 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Олы Әтнә авылы, Совет урамы, 1 йорт;
- сайлау хокукына ия булган Олы Әтнә торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Олы Әтнә торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

1.3. Гражданнар җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда Олы Әтнә авыл җирлеге Олы Әтнә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, сиксән яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү һәм яктырткычлар сатып алу (яктырткычларны, үткәргечләрне ремонтлау, лампаларны алмаштыру, материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

2) Торак пункт территориясен төзекләндерү (Кече Әтнә торак пункты урамнары территориясен төзекләндерү һәм чистарту (үләннәр чабу, агачлар, куаклар, үсентеләр кисү, кисү материалларыннан, чүп-чардан чистарту, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

3) Ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (зиратны карап тоту һәм төзекләндерү (үләннәр чабу, агачларны, куакларны, үсентеләрне кисү, кисү материалларыннан һәм чүп-чардан чистарту, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

«РИЗА» «КАРШЫ»

«Сез 2024 елга гражданнар җыены тарафыннан билгеләнгән 100 000 сум күләмендә гражданнарның үзара салымыннан файдаланылмаган җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту акчасын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Кече Әтнә торак пункты урам юлларын ремонтлау һәм ябу (вак таш сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

«Сез 2024 елга гражданнар җыены тарафыннан билгеләнгән 119 000 сум күләмендә гражданнарның үзара салымыннан файдаланылмаган торак пункт

территориясен төзекләндерү акчасын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) Торак пункт территориясен төзекләндерү (Олы Әтнә торак пункты урамнары территориясен төзекләндерү һәм чистарту (үләннәр чабу, агачлар, куаклар, үсентеләр кисү, кисү материалларыннан, чүп-чардан чистарту, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

«РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълумат-телекоммуникация челтәрендә тубәндаге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Олы Әтнә авылы мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар ул халыкка игълан ителган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башлыгы: Г.Г.Хакимов